

### ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ

«ВТ» хәбәрчесенең ил-көн вакыйгаларына карашы

> 2



### КЫР БАТЫРЛАРЫ

«Урып-җыю җитүгә, йөрәк ешрак тибә башлый, күңел кырга ашкына»

> 3



### ӘНИЛЕ ТОРМЫШ

Әминә әбинең авылда чын исемен белмиләр дә

> 3



### ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 149 (29116) | Чәршәмбе | 11 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


# КЫЙММӘТЛЕ ҖЫЛЫ



Илдар Мөхәммәтҗанов

Көн кадагында

**Җылытты! Дөресрәге, урамда суытты, өйләрдә торбалар кайнарлана башлады. Тик җылылык бирү сезоны килеп җитү бер яктан сөендерсә, икенче яктан көендерә: коммуналь хезмәтләр өчен түләү арта. Кайберәүләргә акчаны җылылык биргәнче үк исәпләгәннәр әнә. Быел ТКХ өчен түләүдә үзгәреш бармы? Яңа елдан соң тарифларны ни көтә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга ачыклык кертте.**

Сентябрь ае бик матур килү сәбәпле, быел җылылык бирү сезоны бераз соңарды. Республика күләмендә барлык йортларга да узган атнада җылы бирә башладылар. Хәер, балалар бакчасы, мәктәп, хастаханә кебек социаль объектларны салкыннар башланганны көтеп тә тормыйча, сентябрь азагында ук җылыта башладылар инде. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, бу атна башында республикадагы барлык балалар бакчаларының – 96, мәктәпләр һәм хастаханәләрнең 93 процентына җылы биргәннәр.

Торбалар кайнарланганны көн саен сагалап торсак, җылылыкка түләү кайберәүләр өчен көтелмәгән хәл булып чыкты. Бу арада социаль челтәрләрдә Казанның кайбер урамнарында яшәүчеләр сезон башланмаган килеш, сентябрь счет-фактурасында әлеге төр хезмәт өчен түләү килгәннән зарлана. Әйтүләренә караганда, фатирның мәйданына карап, салкын торба өчен уртача 2–4 мең сум акча түләргә язганнар.

– Гомуми йорт исәпләгече кую өчен техник мөмкинлекләр булмаган йортларда яшәүчеләр исәп-хисапны, җылылык бирү сезоны кайчан башлануга да карамастан, сигез айга бүлеп исәпләнгән норматив буенча түли. Бу нигездә иске – күбесе авария хәлендәге ике, өч катлы йортларда яшәүчеләргә кагыла. Анда исәпләгечләр урнаштыру өчен коммуникация юк, – дип мәсьәләгә ачыклык кертте «Татарстанның ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры Дмитрий Романов. – Шуңа күрә мондый йортларда яшәүчеләрдән сентябрь аенда җылылык өчен акча түләтүләре канунга туры килә. Гади халык моны аңлап кына бетерә алмый. Чынлап торып исәпләп карасаң, җылылык өчен норматив буенча исәп-хисап ясаучылар, исәпләгеч буенча түләүчеләргә караганда, азрак та түли әле. Һәрхәлдә, күбрәк түгел.

Дмитрий Романов әйтүенчә, әгәр норматив буенча артык күп акча исәпләгәннәр дип шикләнәсез икән, идарәче компаниягә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар гади халыкны кызыксындырган барлык сорауларга ачыклык кертергә тиеш.

Билгеле булганча, соңгы тапкыр коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр ил күләмендә узган елның 1 декабрендә артты. Ут-су, җылылыкка бәяләр гадәттә елга бер тапкыр җәй көне үсә. Россия Хөкүмәте карары нигезендә исә былтыр тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр күтәрелде. Алдагы ел белән чагыштырганда, республиканың кайбер шәһәр һәм районнарында яшәүчеләрнең ут һәм суга киткән чыгымнары 20 процентка кадәр артты. Алга таба коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк. Шулай дип ышандыралар.

> Бәяләргә аерым тукталыйк. Республикада яшәүчеләр өчен электр энергиясенең бәясе, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып, бер кВт/сәгате 4 сум 68 тиен тәшкил итә. Электр плитәләре яки электр җылыту җайланмалары булган йортларда яшәүчеләр өчен бер кВт/сәгате – 3 сум 58 тиен, ә авылда яшәүчеләр өчен – 3 сум 28 тиен. Газның бер куб метры – 6 сум 78 тиен. Су өчен тариф кайсы оешма хезмәт күрсәтүенә карап аерыла. Әйтик, Түбән Кама халкына суның бер куб метры – 32 сум 10 тиен, ә пычрак суны агызуның бер куб метры 21 сум 76 тиен тора. Каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен күпфатирлы йортларда яшәүчеләр аена бер кеше өчен – 103 сум 93 тиен, шәхси торак йортларда яшәүчеләр исә 112 сум 74 тиен түли.

Киләсе елда тарифлар күпмегә артачак? Әлегә бу сорауга төгәл җавап юк. Илнең социаль-икътисадый үсеш фаразларына караганда, 2024 елда коммуналь хезмәтләр өчен түләү 9,8 процентка артырга мөмкин. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетыннан хәбәр итүләренчә, төгәл саннар ел азагына кадәр билгеле булачак.

Акчаны янга калдыру юлы бар анысы. Ул да булса – коммуналь түләүләргә субсидия рәсмиләштерү, ягъни түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару. Республикада халыкка ярдәм итү максатыннан ташлама-субсидияләр бирү каралган. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, мондый ярдәмгә социаль нормалар һәм нормативларны исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала.

Ахыры 2 нче биттә >

## Эш табылыр

2030 елга илдә бигрәк тә авыл хуҗалыгында (300 мең кешегә), сәүдә (200 мең), финанс һәм иминиятләштерү (100 мең), шулай ук күчемсез милек өлкәсендә белгечләргә (100 мең кешегә) ихтыяҗ кимеячәк. Россия Икътисадый үсеш министрлыгы шундый фараз корган.

Министрлыкта билгеләп үтелгәнчә, хезмәт базарына илдәге икътисадый вазгыять, демография, цифрлаштыру, автоматлаштыру, тармакларны үзгәртеп кору йогынты ясый. Фараз корганда, боларның барысы да исәпкә алынган. Кыенлыкларны исәпкә алып, «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын 2030 елга кадәр озайту тәкъдим ителгән.

Әмма башка фикер әйтүчеләр дә бар. Әйтик, Хөкүмәт каршындагы Финанс университеты профессоры Александр Сафонов билгеләп үткәнчә, авыл хуҗалыгында эшче кулларга ихтыяҗ кимемәячәк. Хәтта автоматлаштыру кертелгән очракта да, 2030 елга кадәр һәм аннан соң зур үзгәрешләр булмаячак. «Авыл хуҗалыгында продукция җитештерү күләме артса, хезмәткәрләргә дә ихтыяҗ үсәчәк. Тармактан байтак кешенең махсус хәрби операциягә китүе дә моңа йогынты ясаячак», – дигән белгеч.

## *Тыелу коткарачак*

Киләсе елның 1 июленнән үз исемеңә кредит алуны тыярга мөмкин булачак. Дәүләт Думасы шундый закон проектын беренче укылышта хуплаган. Ул халыкны мошенниклардан сакларга тиеш.

Дума Рәисе Вячеслав Володин әйтүенчә, депутатлар проектны бик күп мөрәҗәгатьләргә җавап йөзеннән әзерләгән. «Халык бу карарны көтә. Закон кешеләрне, шәхси мәгълүматларын урлап, кредит рәсмиләштерүче мошенниклардан саклау мөмкинлеге бирәчәк», – дигән ул.

Володин аңлатып үткәнчә, һәрбер кеше үз исеменә теләсә нинди кредит алуны тыя алачак. Банкларның гына түгел, микрофинанс оешмаларының акчасына да кагыла бу. Ә инде кредитның кирәге чыкса, тыюны гамәлдән чыгарырга мөмкин булачак.

Моның өчен Күпфункцияле үзәккә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша тиешле гариза язып тапшыру күздә тотыла (СНИЛС номерын күрсәтү таләп ителәчәк). Кредит кирәк икән, тагын бер гариза тапшырып, 1 көн эчендә тыюны гамәлдән чыгарырга мөмкин булачак.

## Бушлай кишәрлек

Казанда исәпкә куелган күпбалалы гаиләләрнең 39 проценты бушлай җир кишәрлекләре белән тәэмин ителгән. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматларына караганда, Татарстан буенча бу күрсәткеч 65,34% тәшкил итә.

Бүгенгә республикада барлыгы 72533 күпбалалы гаилә бушлай җир алуга документлар тапшырган. 71843 гаиләне исемлеккә кертү буенча карар кабул ителгән.

Җәмгысы 46611 җир кишәрлеге бирелгән. Шуның 7063е – Казанда.

Нәтиҗә

# Ашаган белми, түләгән белә

**Көзге шыксыз көндә Хөкүмәт йортында эссе җәйгә йомгак ясадылар. Төгәлрәк әйтсәк, лагерьларда ял иткән Татарстан балаларын санадылар. Быелгы җәй хәвеф-хәтәрсез узып китте китүен, ә балалар һәм әти-әниләр канәгать калганмы? Лагерьлар саны арта, начар хәлдәгеләре төзекләндерелә, ә ял итүче балалар саны ни сәбәпле кими?**

**Балаларның җәйге ялы – саннарда:**

- ✓1554 лагерьда җәмгысы 148704 бала ял иткән;
- ✓балалар ялы өчен 2331,9 млн сум акча тотылган (узган елгыдан 330,94 млн сумга күбрәк). Шуларның 203,5 млн сумы – әти-әниләр акчасы;
- ✓38046 кешегә бушлай юллама бирелгән;
- ✓4937 бала – Кара диңгез буенда, 3797 бала – Краснодар краенда, 1140 бала Кырым Республикасында ял иткән.

Бу һәм башка сорауларга Министрлар Кабинетында узган брифингта җавап эзләдек. Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков сүзен санлы күрсәткечләрдән башлады.

– Быелгы җәйге каникулда 148704 бала сәламәтләндерү лагерьларында ял итте. Шул рәвешле планның 91 проценты үтәлде. Балаларны 131 шәһәр яны, 46 палаткалы лагерь кабул итте, шулай ук Мәгариф министрлыгы линиясе буенча 68 меңләп бала җәен 1377 көндезге, ял һәм хезмәт лагерьларында уздырды, – дип сөйләде ул.

Сүз уңаеннан, 2022 елда җәйге лагерьлар 154 мең баланы кабул иткән. Быел бу сан кимрәк. Сәбәбен министрдан сорадык.

– Җәйге ялын лагерьда уздырырга теләүчеләр саны елдан-ел арта гына. Ә быел ял итүчеләр санының кимрәк булуы 13 лагерьда капиталь ремонт эшләре баруына бәйле. Икенче елга ул лагерьларны эшләп бетерәбез, балалар саны да артыр, – дип җавап бирде ул.

Быел Татарстанда җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә җәмгысы 2,3 млрд сум акча тотылган. Узган ел исә бу сумма 19 процентка кимрәк булган.

– Финанслау 330 млн сумга артты. Бу исә туклануны оештыру, медицина хезмәте күрсәтү, канцтоварлар, мәдәни программа һәм коммуналь хезмәтләр өчен чыгымнар артуга бәйле, – дип аңлатты Садыйков.

Тагын бераз санлы мәгълүмат. Быел республика лагерьларында Луганск һәм Донецк халык республикаларыннан килгән 745 бала өчен бушлай сменалар оештырылган.

– Хәзерге вакытта Лисичанск һәм Рубежныйдан килгән 187 бала өчен тагын бер смена уза. Ул 22 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк, – диде яшьләр эшләре министры.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсадуллина быелгы яңалыклар белән таныштырды.

– Елдагыча, без авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдә тәрбияләнүче, тәрбиягә алынган, сәламәтлеге какшаган балалар, төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда актив катнашучы сәләтле укучылар өчен сменалар оештырабыз. Безгә интернат мәктәпләрдә сәламәтлекләре чикле балалар өчен мәктәп яны лагерьлары оештыруны сорап мөрәҗәгать итүчеләр күп иде. Быел без Арча, Әлмәт, Лаеш районнарында 120 бала өчен шундый сменалар да оештырдык, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз



**Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:**

Илдән киткән һәм Киевның канкойгыч нацист режимына җиңү теләп, аларның Россия территориясенә атканына сөенеп, кабахәт гамәл кылган кешеләр шуны аңларга тиеш: монда аларны беркем дә көтми. Инде кайталар икән, Магаданга туры юл көтә.

## РОССИЯДӘ – «СОЦИАЛЬ КИШТӘЛӘР»

**SuperJob хезмәте уздырган сораштыруда катнашучыларның күпчелеге пенсионерлар һәм аз керемлеләр өчен кибетләрдә «социаль киштәләр» оештыруны хуплаган. Мондый киштәләргә вакыты чыккан товарларны куеп, бушлай бирү яки арзан бәядән сату күз уңында тотыла.**

«СОЦИАЛЬ КИШТӘЛӘР»НЕ ХУПЛЫЙСЫЗМЫ?

| Җавап | Барлык катнашучылар | Җенес | | Айлык керем | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ир-ат | Хатын-кыз | 49999 сумга кадәр | 50000–79999 | 80000 сумнан |
| Әйе | 71% | 68% | 75% | 70% | 75% | 67% |
| Юк | 17% | 20% | 13% | 17% | 14% | 22% |
| Икеләнәм | 12% | 12% | 12% | 13% | 11% | 11% |

## *Баланы да аямый*

Татарстанда күз авыруларыннан тилмергән балалар саны арткан. Узган ел табибларга шундый гозер белән 16 мең бала мөрәҗәгать иткән. Алар күбрәк ерактан начар күрү яки әйберләрне аермачык күрмәүдән (астигматизм) интегә икән. Бу хакта журналистларга Республика клиник офтальмология хастаханәсе баш табибы урынбасары Елена Жиденко хәбәр итте.

Хәзерге вакытта республикада 101 мең кеше күз авырулары белән исәптә тора. Елена Жиденко сүзләренә караганда, соңгы арада балалар арасында күз ялкынсыну очраклары да ешрак очрый башлаган. «Хәзерге балалар бөтенләй башкача укый. Шул ук компьютер, гаджетларны да актив кулланалар. Алар аркасында күзләргә авырлык килә», – ди табиб.



shutterstock.com